**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**БЕССОНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БЕССОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 51-2-18, факс 51-2-18

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**29 .11. 2023** **№2**

**2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең Югары Тархан торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Бессоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә:

1. 2023 елның 15 декабрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Югары Тархан авылы, Ленин урамы, 21 йорт адресы буенча урнашкан Югары Тархан авыл мәдәният йорты бинасында, 2024 елда Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең Югары Тархан торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 16 сәгать 00 минутка билгеләнсен.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2024 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең Югары Тархан торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, күп балалы гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына срочная хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?, махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр), волонтерлар) һәм аларның гаилә әгъзалары (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар) һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Югары Тархан торак пунктында Яшел урам, Николаев урамы буенча вак таш, түзелеш комнары сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, эш өчен түләү) юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча поселок эчендәге юлларны ремонтлау);

Югары Тархан торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуына хезмәт күрсәтү) ;

Югары Тархан торак пунктында обелискка мемориаль плитәләр сатып алу һәм урнаштыру.

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында " (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Ю.А. Врясов**